

2026нчы уку елы тәмамланды. Нәтижәләр ясалды. Белем бирvчеләргә, илһамландыручыларга һәм юнәлеш бирvчеләргә зур рәхмәт.
Бvген без гомерен укытучылык эшенә багышлаган Кадошкино районы Большие Поляны (Иса) мәктәбенен математика һәм физика укытучысы Алсу Әнвәр кызы Капкаева турында сойләячәкбез.
Алсу Әнвәр кызы тумышы белән Большие Поляны авылыннан. Шунда анын тормыш юлы башлана, югары уку йортын тәмамлагач, шунда эшкә кайта һәм ботен гомерен туган мәктәбенә багышлый.       - Гаиләдә педагоглар юк иде, әтием - механизатор, әнием - бозау караучы һәм колхозыбызнын торле эшләрендә эшләделәр. Алар минем югары белем алуымны теләделәр. Ә vзем балачактан ук укытучы булырга теләдем. Һәм укытучы гына тvгел, нәкъ менә vзем укыткан педагогым тосле математик. Рус теле һәм әдәбияты укытучысы, грамоталы белгеч, класс житәкчесе Сягидә Әхмәт кызы Ляпинаны, математика укытучысы Сания Мохәммәтжан кызы Капкаеваны искә тошерәм. Бәлки, алар да минем булачак һонәремне сайлауда роль уйнаганнардыр, - дип искә ала Алсу Әнвәр кызы.
Мәктәпне тәмамлагач, Алсу Вяльшина М.Е.Евсевьев исемендәге Мордовия дәvләт педагогия институтынын физика-математика факультетына укырга керә. Беренче курстан сон анын шәхси тормышында vзгәрешләр була: Ринат Шәvкәт улы Капкаевка киявгә чыга, әмма укуын дәвам итә. Практиканы Саранск шәһәре мәктәпләрендә уза, ә бишенче курста студентларны авыл мәктәпләренә жибәрә иделәр, шуна «биш минуттан педагог» булган Алсу Капкаева практиканы туган мәктәбендә уза.
- Укытучы һонәрен алуым турында документ алдым, - дип сvзен дәвам итә әнгәмәдәшем.
- Педагогия институтын тәмамлагач, кече Ватаныма кайттым. Үзем тәмамлаган мәктәптә эшли башладым. Һәм берничә ел элек мине укыткан укытучылар хезмәттәшләр, ярдәмчеләр булдылар. Мин һәрвакыт аларга кинәш сорап морәжәгать итә алуымны белә идем.



[illegible]